| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.09.2022 г. Казань № 649/2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетның «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында» 2016 елның 15 мартындагы 62 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетның «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында» 2016 елның 15 мартындагы 62 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетның 2018 елның 14 мартындагы 62 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Мәгълүматлаштыру бүлегенә (М.Х. Абайдуллин)» сүзләрен «Мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәдә:

2.2 пунктының «а» пунктчасында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктының «б» пунктчасының беренче абзацында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта тиешле күплек-берлек саннарындагы һәм килешләрдәге «кадрлар бүлеге» сүзләрен тиешле күплек-берлек саннарындагы һәм килешләрдәге «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның 3.4.2 пунктчасында «кызыксынган оешмалар» сүзләреннән соң «, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы кулланылырга мөмкин, шул исәптән гаризалар юллау өчен дә» сүзләрен өстәргә;

3.5 пунктның «б» пунктчасында «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.31 пунктта «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар, дәүләт хезмәте һәм мобилизация эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина